**<u>Муса Җәлил</u>**

## Бүләгем

*Тоткынлыкта танышкан бельгияле дустым*
*Андре Тиммерманска*

Кайтса иде гөлләр арасында
Гөрләп үткән көләч көннәрем.
Дускай, сиңа бүләк итәр идем
Илкәемнең иркә гөлләрен.

Бернәрсәм юк минем монда хәзер,
Йортым, бакчам, хәтта иркем дә.
Гөлләр монда бар да кибеп сулган,
Җирләр монда читләр иркендә.

Тик бар минем кара уйлар белән
Тапланмаган керсез йөрәгем.
Йөрәгемнең язгы гөлләр төсле
Җыры булсын сиңа бүләгем.

Үзем үлсәм, исмем, җырым үлмәс,
Ул яңгырар илнең кырында.
Сөйләп илгә тоткын күңелләрдә
Чәчәк аткан дуслык турында.

**1943 ел**